ГЛАВА ШЕЛАНГОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.7, с. Шеланга, 422577

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ШИЛАНГЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Совет ур., 7 нче йорт, Шилангы авылы, 422577

Тел.: (84379) 32-7-48, факс: (84379) 32-7-02.

18.11.2025 г. № № 7

На № от

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге Шилангы торак пункты территориясендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында карар

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлегенең Шилангы авылының бер өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы? - каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, Шилангы авылы М. Горький урамындагы рөхсәтсез чүплекләрне бетерү- дигән сорау буенча 2025 елның 18 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 56 граждан, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 41 кеше кертелде.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен - гражданнар җыенының 41 катнашучысы тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен - җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлегенең Шилангы авылының бер өлешендә гражданнар җыены узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга .
«Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлегенең Шилангы

авылының бер өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы? - каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, Шилангы авылы М. Горький урамындагы рөхсәтсез чүплекләрне бетерү- дигән мәсьәлә буенча карарны танырга.

Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге Шилангы авыл территориясендәге гражданнар җыены нәтиҗәләрен Шилангы авыл җирлеге мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: В.В.Майоров